ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Кама Тамагы
муниципаль районы
***Иске Барыш***
***авыл җирлеге***
**Башкарма**
**комитеты**

422835, Иске Барыш авылы, Үзәк урамы, 15
тел.(884377)30-3-18, ИНН / КПП 1622004570 / 162201001
ОКПО 93064659 ОГРН 1061672003436

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**Исполнительный**
**комитет**
***Старобарышевского***
***сельского поселения***
Камско-Устьинского
муниципального района

422835, с. Старое Барышево, ул.Центральная, 15
тел.(884377)30-3-18, ИНН/КПП 1622004570 / 162201001
ОКПО 93064659 ОГРН 1061672003436

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**04.09.2018** **№ 5**

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы
Иске Барыш авыл җирлеге Башкарма комитетының
2017 елның 19 июнендәге “Стационар булмаган сәүдә
объектларын урнаштыруга шартнамә төзү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ
регламентын раслау турында” 4 санлы карарына
үзгәрешләр кертү хакында

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 19 июнендәге 4 санлы карары белән расланган Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 5 бүлекнең 5.12 пунктындагы 1-3 абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5.12. Шикаять карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шулай ук кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, муниципаль хезмәт курсәтү нәтиҗәсендә бирелгән

документларга кертелгән опечаткаларны һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясе норматив-хокукый актлары, Татарстан республикасы норматив-хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган түләүләрне кире кайтару формаларында;

2) шикаять канәгатьләндерелми.”.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендлар аша халыкка белдерергә:

- Иске Барыш авылы, Үзәк ур., 15 йорт,

- Картапа авылы, Мәктәп ур., 10 йорт,

шулай ук мәгълүмат-телекоммуникация «Интернет» челтәрендә хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуын үз өстемә алам.

Иске Барыш авыл җирлеге җитәкчесе И.Р. Җиһаншин